КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 31 май г.Казань № 421

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасындагы социаль әһәмияткә ия проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2009 ел, 8 июнь, 373 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасындагы социаль әһәмияткә ия проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2009 ел, 8 июнь, 373 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 28 декабрь, 890 нчы; 2010 ел 21 сентябрь, 749 нчы; 2011 ел, 29 июль, 606 нчы; 2012 ел, 9 июнь, 500 нче; 2013 ел, 28 июнь, 444 нче; 2014 ел, 5 июнь, 380 нче; 2014 ел, 8 октябрь, 734 нче; 2014 ел, 18 октябрь, 769 нчы; 2015 ел, 21 сентябрь, 693 нче; 2015 ел, 2 ноябрь, 830 нчы; 2016 ел, 14 гыйнвар, 8 нче; 2016 ел, 3 ноябрь, 812 нче; 2017 ел, 13 июнь, 374 нче; 2018 ел, 19 февраль, 93 нче; 2018 ел, 21 апрель, 277 нче; 2019 ел, 27 февраль, 135 нче; 2019 ел, 30 июль, 633 нче; 2020 ел, 6 март, 174 нче; 2020 ел, 2 июнь, 454 нче; 2020 ел, 30 сентябрь, 889 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Социаль әһәмияткә ия проектларны тормышка ашыруда катнашучы коммерциягә карамаган оешмалар өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты грантларын алуга республика конкурсы турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган Социаль әһәмияткә ия проектларны тормышка ашыруда катнашучы коммерциягә карамаган оешмалар өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты грантларын алуга республика конкурсын үткәрү буенча республика конкурсы комиссиясе составында:

комиссия составыннан А.Г.Барышевны, Ә.Ф.Вәлиеваны, С.М.Захарованы, М.Т.Сәмигуллинны, А.Р.Шәрәповны чыгарырга;

комиссия составына Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары Рамил Камил улы Хәйруллинны кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин